


Үткән атнада Торбеево районы Татар Юнкие авылында озак еллар мәктәп директоры булып тырышып хезмәт иткән Тәнзилә Ахмәт кызы Утешева белән аралаштык. Хөрмәт казанган могаллимә белән күптән аралашып торабыз. Яңалыклар турында сорашкач, бик тә эчтәлекле матур хәбәр турында сөйләп китте. РФ мөселманнары Диния нәзарәтенең мәдәният департаменты житәкчесе Ренат Абясов белән журналист, «Вести FM» радиостанциясен алып баручы, педагогика фәннәре кандидаты Марат Сафаров ( руководитель Департамента культуры Духовного управления мусульман РФ Ренат Абясов белән журналист, ведущий радиостанции «Вести FM», кандидат педагогических наук Марат Сафаров)  Мордовиянен конбатышындагы татарлар яшәгән авылларда командировкада йөргәннәр, икән.

Татар Юнкиендә дә кунакта булганнар, шул исәптән, мәктәп укучылары, укытучылары белән аралашканнар.

Проект  житәкчесе  Ренат Абянов, Марат Сафаров (алар Мордовиянен конбатыш районнарында берничә тапкыр булганнар инде), Танзиля Ахметовна белән Темников татарларынын тарихы, тормышы турында әзерләнә торган «Темников: империяләрнен ныклыгы» басмасынын чыгачагы һәм мәгариф учреждениесендә презентацияләү мөмкинлеге турында фикер алышканнар. Бу тәкъдим анлау һәм ярдәм тапкан. Аннары Ренат Абянов Татар Юнки укучыларына “Тарих һәм тел белеменен мөһимлеге” дип аталган ачык дәрес үткәргән. Жирле укучылар игътибар белән лекцияне тынлаганнар һәм ахырда кызыксындырган сорауларга жавап та алганнар.

Тагы кунак күзенә шундый матур мәк-тәп гадәте барлыгы төшкән: “Жирле мәктәп - якын-тирә торак пунктлар өчен терәк. Анда барлыгы 20 бала укый. Шулай да анда да үз традицияләре бар. Шуларнын берсе - чыгарылыш сыйныф укучылары мәктәпкә картина бүләк итә икән. Һәм бу бүләк ителгән картиналардан тулы бер галерея барлыкка килгән”,- дип тә яза.

Экспедиция вәкилләре Торбеево районы Сыркыдысындагы Хади Такташ музеенда, жирле мәктәптә булганнар. Кунаклар хөрмәтлеләр, тирә-якта ихтирам казанганнар - Равилә Алим кызы Коновалова, Мария Николаевна Бикмаева һәм Светлана Рустам кызы Мустафина белән аралашканнар. Очрашу ахырында Ренат Абянов музейга «Касыйм ханлыгы күләгәсе» китабын тәкъдим иткән. Шулай ук мәктәп укучылары өчен, киләсе визитта, ачык дәрес үткәрү турында килешкәннәр.


АРХИВ


СУДЬБЫ,